КАРАР

2023 елның 28 ноябре, № 2

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 28 ноябрендә, түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылы территориясендә теркәлгән , балигъ булган һәр яшәүчедән, укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2024 елда үзара салымны 5000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Шепшеңәр авылында урам яктыртуны тәэмин итү, энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру һәм башка эшләр белән тәэмин итү;

- Шепшеңәр авылы территориясен төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү;

- Шепшеңәр авылында урам юл челтәрләрен карап тоту, вак таш белән капланган юлларны ремонтлау, чокырлы ремонтлау, вак таш белән каплау җайланмасы, су үткәрү торбасын сатып алу һәм урнаштыру, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

- янгынга каршы җиһазлар һәм комплектлаучы җиһазлар (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, технадзор һәм документлар өчен түләү)сатып алу, урнаштыру һәм тоту;

-сууткәргеч челтәрләрен һәм су күтәрү манараларын ремонтлау, төзү, төзекләндерү, карап тоту (Шепшеңәр авылының артезиан манарасы өчен насос сатып алу, материаллар сатып алу, проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

-Шепшеңәр авылында күперне төзү һәм ремонтлау, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

-Шепшеңәр авылында зиратны территориясен карап тоту, төзекләндерү һәм ремонтлау, зират өчен койма (хуҗалык инвентаре, ремонт өчен җиһазлар һәм материаллар сатып алу), проект-смета документациясен үтәү;

- Шепшеңәр авылында юлларны кардан чистарту (проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

-Шепшенар авылында чишмә территориясен ремонтлау, төзекләндерү , тоту, чишмә өчен будка төзү, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре.

« РИЗА» "КАРШЫ"

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 88 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 45 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
"Әйе» дип гражданнар җыенында катнашучы 45 кеше тавыш бирде;
«юк» дип гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында узган гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре – кабул ителгән дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Шепшеңәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән,укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2024 елда үзара салымны 5000 сум күләмендә кертүне һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүне расларга карар иттек:

- Шепшеңәр авылында урам яктыртуны тәэмин итү, энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру һәм башка эшләр белән тәэмин итү;

- Шепшеңәр авылы территориясен төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү;

- Шепшеңәр авылында урам юл челтәрләрен карап тоту, вак таш белән капланган юлларны ремонтлау, чокырлы ремонтлау, вак таш белән каплау җайланмасы, су үткәрү торбасын сатып алу һәм урнаштыру, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

- янгынга каршы җиһазлар һәм комплектлаучы җиһазлар (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, технадзор һәм документлар өчен түләү)сатып алу, урнаштыру һәм тоту;

-суүткәргеч челтәрләрен һәм су күтәрү манараларын ремонтлау, төзү, төзекләндерү, карап тоту (Шепшеңәр авылының артезиан манарасы өчен насос сатып алу, материаллар сатып алу, проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

-Шепшеңәр авылында күперне төзү һәм ремонтлау, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

-Шепшеңәр авылында зиратны территориясен карап тоту, төзекләндерү һәм ремонтлау, зират өчен койма (хуҗалык инвентаре, ремонт өчен җиһазлар һәм материаллар сатып алу), проект-смета документациясен үтәү;

- Шепшеңәр авылында юлларны кардан чистарту (проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

-Шепшеңәр авылында чишмә территориясен ремонтлау, төзекләндерү , тоту, чишмә өчен будка төзү, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ятмас -Дусай авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.гарифуллина

СОВЕТ ЯТМАС-ДУСАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯТМАС ДУСАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ОГРН 1021607753155
ИНН 1623001685